**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге составына керүче Тәберде Чаллысы авыл торак пунктында узган гражданнар җыены турында**

**КАРАР**

2025 елның 29 октябре №2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында " 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Котлы Бөкәш авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советының 2019 елның 16 октябрендәге X номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Котлы Бөкәш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә", Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге башлыгының « Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Тәберде Чаллысы авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында»гы 2025 елның 17 октябрендәге 2 номерлы карары нигезендә халык җыены карар итте:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Тәберде Чаллысы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, көндезге формада белем алучы студентлардан, тумыштан инвалид булган, 1 группа инвалид, баласыз япа-ялгыз яшәүче яшьләре 80 нән узган өлкән яшьтәге кешеләрдән кала һәм аларның гомуми саны җирлектә яшәүчеләрнең 30% тан артмаган очракта, 600 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен кулланырга:

- урамнарны яктырту җайланмаларын төзекләндерү, урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау;
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- янгынга каршы резервуарлар (янгын сулыклары), янгын пирслары төзү, ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пунктларның башка территорияләрен төзекләндерү;

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы, 32 йорт; Тәберде Чаллысы авылы, Совет урамы, 34 йорт; Мәмли Казак Чаллысы авылы, Үзәк урам, 29 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль хокукый норматив актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Котлы Бөкәш авыл җирлеге башлыгы Г.Г. Нәҗипов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН РЫБНО-СЛОБОДСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОГРН 1021607355446
Р.00-11950/17
СОВЕТ
ХУТЛУ-БУКАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1634001775